ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2019 г. Заинск № 238

**«Ринат Фәрдиев исемендәге махсус ел премиясен бирү турында»**

Зәй муниципаль районының талантлы яшьләренә ярдәм итү, иң яхшы укучыларны бүләкләү, педагогик бергәлекнең инновацион активлыгын стимуллаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Ринат Фәрдиев исемендәге махсус ел премиясен бирүне гамәлгә куярга.
2. Ринат Фәрдиев исемендәге махсус ел премиясен бирү буенча муниципаль конкурс турында Нигезләмәне расларга (кушымта).
3. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә:
- җирле бюджет акчалары хисабына финанслауны тәэмин итәргә;
- ел саен бюджет формалаштырганда Ринат Фәрдиев исемендәге махсус ел премиясен түләүгә 30 000 (утыз мең) сум күләмендә акча күздә тотарга.
4. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravc.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитеты җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

М.К. Вәлиәхмәтова
7-15-89